ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

29.07.2022 ел | Баулы шәһәре | №162

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 124 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 124 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

Административ регламентта (markarga кушымта): 2 «Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты» бүлегендә: 2.8.2 пунктындагы 6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) 38-ФЗ номерлы Федераль законның 5 өлешендә билгеләнгән таләпләрне бозу, әгәр реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен күпфатирлы йортта фатирлар милекчеләренең гомуми мөлкәте кулланылса, 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 5 өлешендә билгеләнгән таләпләрне бозу.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров